**Казан шәһәре Мәскәү районының
“105нче татар телендә белем һәм
тәрбия бирүче катнаш төрдәге
балалар бакчасы”**

# Балалар өчен юл йөрү кагыйдәләре буенча куелган театраль күренеш:

## “Йомры икмәк-юл кагыйдәләрен бозучы”

**(мәктәпкә әзерлек төркеме)**

**Тәрбияче: Хисматуллина Г.И.**

**Алып баручы:** -Бер авылда – әби белән бабай яшәгәннәр.

**Бабай:**-Безнең гаиләдә ике кеше-әби белән бабай яшибез.

**Әби:**-Без бабай белән дус яшибез. Тик безгә күңелсез, яңыбызда кызыбыз белән улыбыз юк.

**Бабай:**-Әби, әйдә, камырдан бер бала яса! Безгә күңелле булыр.

**Алып баручы:**-Әби йомры-икмәкне пешереп, аңа кинәш бирә:

**Әби:**-Йомры-икмәк, син өйдән чыгып китмә, юллар киң, анда машиналар да куп. Урамга чыкканчы сиңа юл йөрү кагыйдәләрен белергә кирәк.

**Алып баручы:**-Әмма, йомры-икмәк әбинең сүзен тыңламаган, юл буйлап тәгәрәп киткән.

**Йомры-икмәк (җыр җырлый):**
"Миң йомры-икмәк, миң йомры-икмәк
Тәгәрәп йөри алам.
Тик әби-бабай өендә
Озак утыра алмам.
Машинадан курыкмыйм,
Урамда йөри алам.

**Йомры-икмәк юлга чыга-"Автомагистраль" билгедә тукты, каршыга куян сикереп килә.**

**Куян:**-Тукта әле йомры-икмәк,
Син кая ашыгасың?
Монда йөрергә ярамый,
Әллә шуны белмисең?
Менә бу **"Автомагистраль**"
" Юл йөрү кагыйдәсе исендә тот,
Бик каты һәм таләпчән!
Җәяуле өчен-тротуар!
Син юл кырыеннан бар!
Шәһәр чите-шосседа
Тротуар бөтенләй юк.
Кешеләр сул яктан бары,
Транспортка каршы хәрәкәт итәргә тиеш!"
**Йомры-икмәк куяны тыңламаган, тәгәрәп алга китте һәм җыр җырлый:**
" Миң йомры-икмәк, миң йомры-икмәк
Тәгәрәп йөри алам.
Тик әби-бабай өендә

Озак утыра алмам.
Машинадан курыкмыйм,
Урамда йөри алам".

**"Җәяуле юлы"билгедә тукты, каршына бүре чыга.**

**Бүре:**- Тукта әле йомры-икмәк,
Син кая ашыгасың?
Бу бит **"Җәяуле юлы",**
Истә тот бу билгене:
"Аклы-каралы юл буйлап
Җәяуле горур атлый.
Чөнки белә-шушы билге
Гомерен уяу саклый.
Күрәсең, аңы йөртүче
Күрмәс дип уйлаганнар.
Кырыйларын әле тагын
Сарыга буяганнар.
Әлеге билге кисәтә
Йөртүчене бу хакта:
-Игътибарлы булыгыз,-ди
Җәяуле үткән чакта!"

**Йомры-икмәк бүрене дә тынламыча, тәгәрәп киттә һәм җыр җырлый:**

"Миң йомры-икмәк, миң йомры-икмәк
Тәгәрәп йөри алам.
Тик әби-бабай өендә
Озак утыра алмам.
Машинадан курыкмыйм,
Урамда йөри алам".

**"Җир асты" юлыда тукты, каршына аю чыга.**

**Аю:**-Тукта әле йомры-икмәк,
Син кая ашыгасың?
Болай йөрсәң, син бик тиздән
Машинага эләгәсең!
"Монсы тагын нинди баз,
Гүя, җәнлек авызы.
Төшләре дә бар бугай,
Бәлки, ул бик явыздыр?!
Ләкин никтер бу базга
Төшәләр көлә-көлә.
Баскычы бар-нинди баз бу?
Җавабын, йә кем белә?"

-Әе, бу бит: “Җәяүлеләрнең җир асты” кичүе.

**Йомры-икмәк аюны тыңламаган, тәгәреп юлга китә һәм җыр җырлый:**

“Миң йомры-икмәк, миң йомры-икмәк
Тәгәрәп йөри алам.
Тик әби-бабай өендә
Озак утыра алмам.
Машинадан курыкмыйм,
Урамда йөри алам”.

**Каршына “Светофор” чыга.**

**Светофор:**-Тукта әле йомры-икмәк,
Сиң кая ашыгасың?
“Бу билгене күрми үтү
Мөмкин түгел һич кенә.
Кызыл, сары, яшел күзле
Ак өчпочмак ич менә!
Кызыл әйтер: “Туктап кал!”
Сары әйтер: “Игътибар!”
Яшел әйтер: “Юл ачык,
Карап кына атлап чык!”

**Йомры-икмәк “Светофорны” да тыңламаган, тәгәрәп юлга чыга һәм җыр җырларга башлады, юлга машина чыга-йомры-икмәкне тапты...**

**Алып баручы:** -Йомры-икмәк светофорны тыңламыйча алга чапкан һәм машина астына эләккән.

“Юлны аркылы чыкканда,
Йомры икмәк чак котыла.
Бәрелеп һәм кысылып,
Өенә кайтып егыла”.

**Йомры-икмәк:**-Юл йөрү билгеләрен беләсәкмен, башка юлга йөгереп чыккмам.

**Әкият геройлары сәхнә уртасына чыгып балаларга сорау бирәләр.**

**Алып баручы:**-Балалар, йомры- икмәк нинди юл йөрү кагыйдәләрен бозган? (Йомры -икмәк юл йорү кагыйдәләрен һәм юл билгеләрен белмәгән. Шуңа күрә ул машина астына эләккән).

**Йомры-икмәк:** -Җәяүлеләр кайдан йөрергә тиеш? (Җәяүлеләр бары тик тротуардан гына йөрергә тиеш. Каршы килүчеләр белән бәрелешмәч өчен, тротуарның уң ягыннан барырга кирәк).

**Куян:**- Юлны кайдан чыкарга кирәк? (Юлны “зебра” яки “Җәяүлеләр юл кичүе” билгесе булган урында гына аркылы чыгарга ярый. “Җир асты кичүе” һәм “Җир өсте кичүе” билгеләре дә юлны чыгарга ярдәм итә).

**Бүре:**- Юлга ни өчен кинәт кенә йөгереп чыгарга ярамый? (Машиналар юлына йөгереп чыгарга ярамый, чөнки юлда көтмәгәндә машина килеп чыгуы бар. Транспорт туктап өлгерә алмаса, һәлакәт булырга мөмкин).

**Аю:**-Сез нинди транспорт төрләрен беләсез?(Транспорт төрләре: җир өсте, җир асты, су транспорты, тимер юл транспорты, һава транспорты).

**Светофор:**-Балалар, без нинди юл йөрү билгеләрен белергә тиеш? (Җәяүле балалар түбәндәге юл билгеләрен белергә тиеш: “Җәяүлеләр юл кичүе”, “”Җир аста кичүе”, “Җир өсте кичүе”, “Велосипедларга хәрәкәт итү тыела”, “Велосипед юлы”, “Җәяүлеләргә хәрәкәт иту тыела”).

**Бөтен геройлар һәм балалар:**

**“Сәламәт булыйм дисән,**
**Юл йөрү кагыйдәләрен**
**Яттан белергә кирәк!”**

**Бурычлар:**

**1.**Кызыксындыру формасын кулланып юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту.
**2.**Балаларны геройларның хис-тойгыларын кәефләрен биррергә өйрәтү.
**3.**Һәрбер персонаж өчен хәрәкәт, жест формаларын тудыру.

**Катнашучылар:**

1.Алып баручы- Полина

2.Бабай-Азат

3.Әби-Азалия

4.Йомры-икмәк- Ранель

5.Куян-Анвар

6.Бүре-Денис

7.Аю-Данис

8.Светофор-Маргарита

9.Машина-Кирилл

**Балалар:**

10. Имиль

11. Адель

12. Евгений

13. Елена

14. Ильдар

15. Анжела

## Кулланылган әдәбият:

**1.**К.В. Петрова “Как научить детей ППД”.  Планирование занятий, конспекты, кроссворды, дидактические игры, 2013.
**2.**Сочинения – сказки по Правилам дорожного движения.
**3.** “Серле китап”- “Таинственная книга” перевод С. Гайнуллиной.
**4.**Т.Ф. Саулина “Три сигнала светофора”.
**5.** Н. Пикулева “Дорожная азбука”